**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел.+7(84396) 2-58-00 тел./факс +7(84396) 2-58-42, email: Ispolkom.Cheremshan@tatar.ru; http://cheremshan.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.09.2022 ел **Чирмешән авылы** № 301

**Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге, норматив таләпләргә туры килә торган автомобиль юлларының озынлыгы өлеше» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын раслау турында**

Татарстан Республикасының бүленгән ситуацион үзәген булдыру һәм эшләтү буенча эшче төркем киңәшмәсенең 01.06.2022 елдан № РН-12-135 беркетмәсенең 5 пунктын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты, **КАРАР ЧЫГАРА:**

1. Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге, норматив таләпләргә туры килә торган автомобиль юлларының озынлыгы өлеше» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламентын расларга кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чирмешән муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Кәримовка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.Н. Шәйдуллин

Килешенде:
инфраструктура үсеше
бүлеге начальнигы Х.С. Сәлахов

Әзерләде:
инфраструктура үсеше
бүлеге баш белгече Э.Б. Җиһаншина

Тикшерде:
район Советының
юридик бүлеге начальнигы Т.В. Рунова

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
башкарма комитеты карарына
кушымта
«____» __________ 2022 ел, № _____

**Хисап чорында (узган ел) «Җирле әһәмияттәге, норматив таләпләргә туры килә торган автомобиль юлларының озынлыгы өлеше» күрсәткечен җыю һәм мониторинглау механизмы буенча Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органы эшчәнлеге регламенты**

## I. Гомуми нигезләмәр

Әлеге Регламент хисап чорында (узган ел) (алга таба – Регламент) «Җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы өлеше» күрсәткечен мониторинглау өчен эшләнгән.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында Күрсәткеч мәгънәләрен җыю һәм мониторинглау өчен җаваплылык үзәге булып Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тора (алга таба - Башкарма комитет).

Күрсәткеч мәгънәсе турында мәгълүмат җиткерүчеләр - Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының авыл җирлекләре башлыклары.

Күрсәткеч мәгънәләре турында мәгълүмат бирү формасы Регламент кушымтасына туры килергә тиеш. Муниципаль район буенча агрегированиелангән мәгълүмат үзенә кергән җирлекләр мәгълүматы нигезендә формалаша һәм регламент режимында Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан «Норматив таләпләргә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы өлеше гомуми файдаланудагы җирле автомобиль юлларының гомуми озынлыгында, процент» күрсәткеченең фаразланган күрсәткечен килештерү өчен «Идарә нәтиҗәлелеген бәяләү» мәгълүмати-аналитик системасында аларның эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү өчен шәһәр округлары һәм муниципаль районнар башлыкларының докладларын әзерләү кысаларында тутырыла. Бер үк вакытта, алынган һәм тапшырыла торган мәгълүмат Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында башкарма комитет җитәкчесе боерыгы белән билгеләнгән мәгълүмат җыю һәм мониторинглауны тәэмин итә торган җаваплылык үзәге тарафыннан архивлана.

## II. Аңлатмалар аппараты

Әлеге модель актта кулланыла торган терминнар һәм билгеләмәләр «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 08.11.2007 ел, № 257-ФЗ Федераль законда китерелгән.

Форма № 3 - ДГ (мо) - «Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм ясалма корылмалар турында мәгълүматлар» федераль статистик күзәтү формасы, ул Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең 2021 елның 30 июлендәге 458 номерлы боерыгы белән расланган.

## III. Мәгълүмат җыю тәртибе, сроклары һәм тапшыру формалары

Күрсәткечне исәпләү өчен түбәндәге мәгълүматлар кулланыла:

хисап елының декабрь ахырына транспорт-эксплуатация күрсәткечләренә норматив таләпләргә туры килә торган муниципаль районда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы, км;

хисап елының декабрь ахырына муниципаль районда җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гомуми озынлыгы, км.

Башкарма комитет Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына № 3-ДГ(мо) формасы буенча белешмәләрне дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең (алга таба - Росстат) территориаль органына тапшыру көненә кадәр бер айдан да соңга калмыйча рәсми запрослар җибәрү юлы белән җирле әһәмияттәге юллар турында белешмәләр төзи.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләре башлыклары мәгълүматлары Башкарма комитет җаваплылыгы үзәгенә – инфраструктур үсеш бүлегенә электрон документ әйләнеше системасында яки электрон почта адресына тапшырыла.

Җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты Кушымта нигезендә электрон формада кергән мәгълүматны исәпкә ала. Мәгълүматларны җыю һәм эшкәртү нәтиҗәләре буенча җаваплылык үзәгенең вазыйфаи заты ел саен хисап елыннан соң килүче 25 апрельдән дә соңга калмыйча «Идарә нәтиҗәлелеген бәяләү» мәгълүмати-аналитик системасында ирешелгән күрсәткечләр тутыра.

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының авыл җирлекләре чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге авыл җирлеге администрациясенең Россия Федерациясе законнары нигезендә махсуслаштырылган оешмалар белән төзелгән контрактлары (шартнамәләре), шулай ук муниципаль заказны урнаштыру өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге үз эченә ала:

- автомобиль юлларының техник торышын бәяләү;
- автомобиль юлларын карап тотуны һәм ремонтлауны проектлау;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау эшләрен башкару;
- автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләрне кабул итү.

Кушымта

1. Мәгълүматларны мониторинглау формасы

| № п/п | Муниципаль районның авыл җирлеге исеме | Норматив таләпләргә туры килгән җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының озынлыгы өлеше | | |
|---|---|---|---|---|
| | | % | Юлларның гомуми озынлыгы, км | Норматив хәлдәге юлларның озынлыгы, км |
| 1 | | | | |
| 2 | | | | |